ГЛАВА КАРАКАШЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Сирина Батыршина,,д.33,
с.Каракашлы 423961

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КӘРӘКӘШЛЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Сирин Батыршин урамы, 33 йорт,
Кәрәкәшле авылы, 423961

Тел.:(85593) 4-21-21, факс:4-21-21, e-mail: Karak.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«24» октябрь 2025 ел № 4

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге составына керүче Урал торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 26 маддәсе нигезендә, КАРАР БИРӘМ:

1. 2025 елның 12 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы, Ютазы районы, Урал бистәсе, Урал урамы, 10В йорт адресы буенча урнашкан күпфункцияле үзәк бинасы янында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Урал торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлегенең Урал торак пункты территориясендә 2026 елда яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, махсус хәрби операциядә катнашучылардан, махсус хәрби операциядә катнашучыларның якын туганнарыннан (ата-аналарыннан, тормыш иптәшләреннән), Россия Армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә сез ризамы?:

- Урал торак пунктында торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Урал торак пунктында юлларны кардан чистарту (эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- Урал торак пунктында су белән тәэмин итү һәм канализация системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау; халыкка су ташу һәм бирү (суүткәргеч челтәрләрен ремонтлау (материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү);

- Урал торак пунктында урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны (урамнарны энергияне саклый торган лампалар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү) ремонтлау".

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге башкарма комитетына Урал торак пунктында гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне тәэмин итәргә

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http://jutaza.tatarstan.ru.), http://pravo.tatarstan.ru / электрон адресы буенча Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында кабул ителгән көннән алып 5 көн эчендә урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы М.Н.Мусин